

ISSN 0868-4545

Салават күпере

Җилдерик без атларда!..

Айгыр, бия, тай, тулпар, алаша, колын, юртак, елкы...

Арба, тарантас, чана, дилбегә, йөгән, ыңгырчак, дага, кендек, тәгәрмәч, авызлык, тышау...

Алмачуар, Сөлек, Айбаш, Өлгер, Җирәнкәй...

Өлкәннәр әйтмешли, кыскасы — һәм башкалар, һәм башкалар...

Син инде, кадерле дускай, сүзнең ни хакында барачагын шундук сизендең, төшендең — шулай бит?!

Әйе, әйе, сүзебез, әлбәттә, АТ турында.

Татар халык язучысы Мөхәммәт Мәһдиев «Сабантуй» исемле фотоальбомда болай дип язган иде:

«Ат — татар халкының гомерлек юлдашы, иптәше, туйдыручысы булган. Татар халкы атка бервакытта да мал-туар дип карамаган.»



Чынлап та, бик хак сүзләр. АТ сугыш дигән афәтле елларда да, тыныч чорларда да һәрчак тугры хезмәт итте һәм хәзер дә ул кешенең аерылмас юлдашы. АТ — иң күңелле бәйрәмнәребезнең берсе булган Сабантуйда гаярь малайларны атландырып бәйгедә катнашучы да. Хәтта АТ «табиб» та әле: бия сөтеннән әзерләнгән кымыз бик күп авыруларга дәва.

Әүвәлге заманнарда малай-шалайлар төннәрен АТ сакларга баруны зур мәртәбә санаганнар. АТка атланып йөрү, АТны елгада коендыру... Авыл малае өчен әйтеп бетергесез куаныч, сөйләп бетергесез сөенеч түгелмени бу?!


«Асыл, гаярь ир-егетнең төшенә дә ат керер,» — диләр.

Әйдә, дускай, ким-хур булып йөрмик, җай чыкканда җилдерик без атларда!..


© "Салават күпере", 1999 ел













Ат җигә




Аттан башлыйк
    без сүзне:
Ат була
    ике күзле.
Ике колак,
    дүрт аяк,
Һәр аяк саен тояк.
Тоякка
    каксаң дага,
Бахбай
    таймыйча чаба.
Башын сыйпап
    һәм сөеп,
Аңа йөгән кидереп,
Сыртына
    ыңгырчагын
Салгач,
    шлея тагын
Ыңгырчакны
    тарттыра,
Кымшанмыйча
    ат тора.
Камыт кирәк
    муенга,
Тагын
    бәйләп куярга
Чөелдереге белән.

Эдуард Мостафин

Беләсеңме?

Камыт
 булмасын түбән.
Бер дуга,
 ике тәртә
Беркетелә камытка.
Тәртәдән
 ыңгырчакка
Аркалык үткәрелә —
Тәртәлек
 күтәрелә.
Тәртәдә
 бавырлык та
Бүлешә авырлыкны.
Тәртәләр
 таралмаска,
Беркетелә
 ул аска.
Йөгәнендә дилбегә,
Дилбегә
 тоткан белә:
Атны кая борырга,
Кая алып барырга.
Бик кызып китсә
 бахбай,
Тота авызлык,
 ай-һай!



Рәссам Юрий ДЕНИСОВ





Ләбиб Лерон

Киребеткән

Мин бер колынны беләм. Киребеткән исемле. Киренең дә киресе инде менә. «Үз киресенә каткан!» — диләр андыйлар турында.

— Бар, дусларың белән болында уйнап кайт! — ди аңа әнисе Гөлбияттәй.

— Фи! Көтү булып йөрергә мин җүләр түгел лә! — дип кенә җиффәрә Киребеткән.

— Бер очтан болында хуш исле, тәмле үләннәр белән сыйланып кайтыр идең, — дип әйтеп тә карый Гөлбияттәй.

— Мин ач түгел әле! — ди Киребеткән.

Башка колыннар шаяра-көлә куышлы уйный. Киребеткән йоклый. Бүтән колыннар күбәләкләр куып йөри. Киребеткән төш күрә. Колыннар су коена. Киребеткән йокыдан уяна.

— Әни! — дип кычкыра ул. — Ашыйсым килә!

Гөлбияттәй эш белән мәшгуль. Ишетми.

— Әни, дип әйтәм! Нәни корсагым ашарга сорый! — ди Киребеткән.

Әнисе ишетә, ниһаять.

— Әнә, табакта солы боткасы бар. Аша шуны, — ди Гөлбияттәй.

— Юк, ашамыйм! Солы боткасы ашарга мин җүләр түгел лә! — ди Киребеткән.

— Алайса, ашама! — ди әнисе.

— Юк, ашыйм! Ашамаска мин җүләр түгел лә! — ди Киребеткән. Шулай ди дә, тиз генә табакны ялтыратып та куя.

— Әни! Пепси-кола, лимонад, фанта... тагын... газлы су эчәсем килә! — ди Киребеткән.

— Алары нинди су тагы? — дип гаҗәпсенә Гөлбияттәй.

— Фирмир Гапсамат малае шуларны гына эчә! — ди Киребеткән.

— Беренчедән, син фермер малае түгел. Икенчедән, әнә, тагаракта чишмә суы. Эч шуны! — ди Киребеткәнгә әнисе.


— Юк, эчмим! — ди Киребеткән. — Минем уйныйсым килә!

Ул шулай ди дә, башка колыннар янына чаба. Ләкин бик тиз әйләнеп тә кайтта.

— Нишләп алар минем белән уйнамыйлар? Нишләп йоклыйлар алар? — ди Киребеткән әнисенә.

— Син киреләнеп йоклаганда алар уйнадылар, хәзер алар киерелеп йоклыйлардыр инде, — ди Гөлбияттәй.

— Җүләрдер алар, — ди Киребеткән һәм эченнән генә «Минем кебек» дип уйлап куя.



Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ



Ләбиб Лерон

На-а, бахбай!

— На-а, бахбай! На-а-а...

Иңемдә канатлармыни — очам гына!

Томырылам, ук шикелле.

Җил, ялкын телләре ясап, чәчләремне уйнаклата.

Сәдәфләре ычкынган күлмәгем җилфер-җилфер килә.

Рәхәт!

Шундый рәхәт!

— На-а, бахбай! На-а-а...

Мәтәлеп төшүдән куркып, аяк астындагы юлга карамаска тырышам. Карашым алга төбәлгән...

— На-а, бахбай! На-а-а...

Юл читендәге үләннәр, чәчәкләр — һәммәсе бергә миңа сокланып карыйлар төсле. Кем белә, бәлки, көнләшәләрдер дә әле. Көнләшсәләр көнләшәләр инде, бернишләр хәл юк. Аларның, минем шикелле, малай булып тумаганнарына мин гаепле түгел...

— Әһә-һә-һә-ә-әй! На-а, бахбай! На-а-а...

Тузаннар туздырып, капка төбебезгә кайтып туктадым. Көнбагыш чүбен әле сулга, әле уңга «тфү»ләп утырган кунак малае Ринат (күршеләргә кайткан) эскәмиядән торды да, күзләрен ялтыратып, минем янга килде.

— Дай, а, я тоже чуть-чуть юреп килем!

— Мә. Жәл түгел. Бар, җилдереп кил әйдә бер!

Кунак малае минем зәңгәр велосипедка җәһәт кенә менеп атланды да кузгалып китте.

Ат шундый килешер иде аңа. Миңа да!

Рәссам Илдар НӘФИЕВ



© "Салават Күпере", 1999



Атларның да була төрлесе

Дөньядагы иң көчле ат — Рәсәй аты Форс. Ул 1951 елда махсус әзерләнгән арбага салынган 23 тонна йөкне (ком тутырылган капчыкларны) 35 метр тартып бара.

Иң зур гәүдәле ат — Бруклин Сюпрем кушаматлы ат. Брабансон дигән токымнан булган бу атның җирдән биеклеге — 198 сантиметр. Гәүдә әйләнәсе — 310 сантиметр. Авырлыгы — 1374 килограмм.

Иң кечкенә гәүдәле ат — Филадельфиядәге бер фермерныкы. Атның җирдән биеклеге 35 сантиметр, авырлыгы 6 килограммнан аз гына артык.

Иң озын гомерле ат — Билли кушаматлы. Ул 62 яшендә үлә (1822-1884). Атлар гадәттә уртача алганда 30-40 ел яшиләр.


Кемнең аты ахыргы?

Табышмак

Ике бик шәп атның хуҗалары чабышмакчы булганнар. Бу чабышның кызыгы шул: кемнең аты соңрак килсә, шул атка ун мең сум акча бирергә булганнар. Икесе дә, атларына менеп, чабып китә торган урынга килгәннәр. Чабышырга әмер булган, әмма чабышучылар урыннарыннан кузгалмыйлар да икән.

Бераз торгач, тамаша күрергә килгән кешеләрдән берсе, яннарына барып, чапмауларының сәбәбен сораган. Тегеләр эшнең нәрсәдә икәнлеген аңлатканнар. Сораучы кеше бары ике генә сүз әйткән. Шуннан соң чабышучылар, атларын бөтен көчләренә кыйный-кыйный, чабып та киткәннәр. Берсенең аты артта калган, шуңа ун мең сум акча биргәннәр. Әлеге кеше ат хуҗаларына нинди сүзләр әйткән?

– Атларыгызны алмаштырыгыз! – диген. (Кеше атына күчеп атлангач, һәр хуҗа аны беренче китерергә, шулай итеп, үз атын артта калдырырга тырышкан.)



Сабан туе... Сабан туе!..

(Әдипләребезнең әсәрләреннән өзекләр)

Сабан туе — халык бәйрәме, аннан бер җан иясе дә читек күңел белән китәргә тиеш түгел... Сабан туе көннәре якынлашканда атның «аягын кыздыралар»... Сабан туе программасының иң кызык өлеше — ат чабышы. Моңа 10-15 яшьлек малайлар катнаша.

Мөхәммәт Мәһдиев.

Бәйгеләрдә — җилдән җитез атлар,
Дагалардан очкын чәчелә.
Ат өстендә килгән үсмерләрнең
Ут кабынып сыман чәченә.

Харрас Әюпов.

...Томырылдык тормыш эченә без
Сабан туе атлары сыман.

Зөлфәт.

Учлап-учлап туфрак ата
Тояклар кыеп кына.
Тезгеннәр зеңләп тартылган,
Киләбез тыеп кына...

Ләис Зөлкарнәй.



Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ





Атларның борынгы бабалары

Эогиппус. Атларның тәүге бабасын шулай атыйлар. Ул карап торышка төлке хәтле генә булган: башы кечкенә, муены кыска, аркасы бөкре, тиресе буйлы-буйлы, алгы аякларының бармаклары дүртәү, арткыларыныкы — өчәр. Эогиппус илле миллион ел элек Төньяк Американың дымсу урманнарында яшәгән, яфраклар белән туенган.

Эогиппустан соң орогиппус, аннары гәүдәсе сарык зурлыгында булган мезогиппус токымы дөньялыкка килгән. Планетаның күпчелек өлешен алып торган дымсу тропик урманнар юкка чыга башлагач, далалар һәм үләннәр пәйда була. Мезогиппуслар, урман чытырманнарыннан дәррәү кузгалып, иркенлектә яшәүгә күчәләр, үләннәр белән тукланалар. Даладагы бүреләр үзләрен һәрдаим эзәрлекләү сәбәпле, алар җитез чабарга өйрәнәләр. Аяклардагы артык бармакларның кирәге калмый: бармаклар акрынлап кими һәм нәтиҗәдә һәр аякта берәү генә кала. Атлар бертояклы хайваннарга әверелә.

Еллар уза тора, токымнар үзгәрә тора: меригиппус, гиппарион (зебрадан аз гына тәбәнәк), плиогиппус. Соңгысыннан бүгенге атлары быз токымы барлыкка килә.

Рәссам Илдар НӘФИЕВ

Шәһәр... ат исемен йөртә

Буцефал — Александр Македонскийның яраткан аты. «Буцефал» «үгезбаш» дигән мәгънәне аңлата. Маңгае киң булганга шундый исем кушканнар. Безнең эрага кадәр 326 елда Гидасп тирәсендә һиндләр белән бәрелештән соң, артык киеренкелек нәтиҗәсендә, Буцефал җан бирә. Ат үлгән урында Македонский Буцефал дигән шәһәргә (дөньяда ат исемен йөрткән бердәнбер шәһәр) нигез сала.

Инцитатус («Җитезаяк») — бу ат шуның белән данлыклы, ул Рим императоры Каллигуланың мәгънәсез теләге аркасында... сенатор була. Бәлки империядә Инцитатус консул дәрәҗәсенә дә ирешкән булыр иде, әмма аның дуамал хуҗасын үтереп өлгерәләр.





Берта Липанович

Хыял

Пони бүләк итсәләр —
Нишләргә белер идем:
Балконда яшәтермен,
Пони фил түгел инде.

Бергә сөйләшер идек,
Ашар идек без шикәр.
Шулчакта әйтер идем:
— Поникаем, йә, ни хәл?




Ягымлы бахбай

Бик ягымлы бахбай
Килә башын чөеп.
Исәнләшә үзе:
«Сәлам! Сәлам!» — диеп.

Прәнник белән аны
Тәмләп сыйлап-сыйлап,
Без сөйләштек, әйе,
Матур сүзләр сөйләп.

Моңсуланып кына
Саубуллашты бахбай:
«Сәламәт бул, яме!
Сау бул, батыр малай!»



Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ

ТОКЫМЛЫ АТЛАР





Саф нәселле гарәп аты

Атланып йөри торган атлар арасында иң борынгы токымнардан берсе. Мондый атларның җирдән җилкә калкымына хәтле булган биеклеге 140-156 сантиметр тирәсе.


Бу атларны IV-VI гасырларда Гарәп ярымутравының үзәк районнарында яшәүче күчмә гарәпләр (бәдәвиләр) үрчетә башлаган.

Саф нәселле гарәп атларын бүгенге көндә дөньяның бик күп илләрендә очратырга мөмкин.

Рәсәйдә әлеге атлар XVIII гасырда күренә башлый. Саф нәселле гарәп атының берничә төре бар. Рәсемдә: сулда — сиглави, уңда — кохейлан.

Авыр йөк аты

Күп тонналы авыр йөкләрне тартып барырга сәләтле мондый атлар иң әүвәл XVIII-XIX гасырларда Көнбатыш Ауропада үрчетелә. Рәсәйгә аларны XIX гасыр уртасында алып кайта башлыйлар. Авыр йөк атының авырлыгы 800-900 килограммга, хәтта бер тоннага җитә. Першерон токымы (сулдагы рәсем) Франциядә үрчетелә. Рәсәйгә бер гасыр чамасы элек китерелә. Авырга җигелә торган совет токымы (уңдагы рәсем) Бельгия авыр йөк атларын (брабансоннар) җирле атларның затлыраклары белән кушу нәтиҗәсендә барлыкка килә. Першероннан күпкә авыр булган әлеге яңа токымның түш әйләнәсе ике метрдан артып китә.









Орлов һәм Урыс юртаклары

Баштагы мәлләрдә юртак токымлы атларны авыр экипажларны йөртүдә файдаланганнар. XVIII гасыр ахыры – XIX гасыр башында үрчетелә башлаган Орлов юртагы дөньякүләм шөһрәт казана. Зур гәүдәле, матур һәм елгыр бу юртакны төрле төбәк-илләрдән сорап киләләр. Орлов юртагының җирдән җилкә калкымына хәтле биеклеге 160 сантиметр, түш әйләнәсе — 183 см.

Рәсемдә: уңда — «Павлин» кушаматлы юртак, сулда — Орлов байталы.

Ахалтекин

Бүгенге төркмәннәрнең борынгы бабалары үрчетә башлаган яңа токымлы атларга Ахалтекин исеме Копет-Дагның төньяк тармагындагы Ахалтекин оазисын күздә тотып кушылган.

«Болан» муенлы, озын нечкә аяклы бу токымның җилкә калкымына хәтле биеклеге 154 сантиметр, түш әйләнәсе 167 см.

Карап торышка нәфис кенә булып күренгән әлеге атлар югары куәт белән эшләргә бик тә сәләтлеләр. 1935 елда ахалтекиннарга атланган төркмән җайдаклары Ашхабадтан Мәскәүгә кадәр булган 4300 км араны 84 көндә үттеләр.








Айсылу Лероновага 15 яшь.
Ул Казандагы Ш.Мәрҗани исемендәге 2 нче татар гимназиясендә укый. Ул күбегезгә телевизор аша («Тамчы» тапшыруын күздә тотып әйтүебез) яхшы таныш. Айсылу фортепьянода, мандолинада уйнарга һәм, әлбәттә, рәсемнәр ясарга ярата.
Атларга багышланган кайбер рәсемнәрен сезнең игътибарга тәкъдим итәбез.






Наз



Очыш



Әнием янында



Аткай

Гәрәй РӘХИМнең кайбер китаплары:

Вәгъдә	1967
Чәчәк сатучы малай	1968
Хәтер	1970
Шатлык елы	1972
Гөрләвек	1974
Моңнарым	1978
Чәчәк тәкыя	1981
Туган йортта	1983
Җәй уртасы	1985

Рәссам Фәрит Муллахмәт

Кадерле дускай!

Журналның урта битен ипләп кенә алып, кара сызыклар буенча кисегез, сары сызыклар буенча бөкләгез дә, килеп чыккан кисәкләрне, бит саннарына карап, китап итеп җыегыз. Булгач-булгач, чын китап булсын — уртасын ике урыннан төпләп куегыз.

©«Салават күпере китапханәсе.



Яшенле яңгыр


Болыт килә үкереп,
Дөбер-дөбер иттереп.
Яшеннәрен уйната,
Шомлы уйлар уйлата.


Авыл турына җитә,
Яңгыр тетепме тетә!
Бер почмакка посабыз,
Бер-беребезне кочабыз.

Яшен «гөлт» итеп куя,
Йөрәк «дерт» итеп куя.
Күк күкери дөбердәп,
Без ятабыз дерелдәп.

Сөйләшәбез тын гына,
Тын гына, мыштым гына:
«Яңгыр бер узып китәр,
Болыт таралып бетәр.

Менә инде шул чакта
Без дә җаен табарбыз,
Күк күкрәгән кебек итеп
Дөбер-шатыр чабарбыз!»





Шагыйрь, Г. Тукай бүләге иясе
Гәрәй Рәхим
улы Даут (ат өстендә) белән.

Тимер торна

(Тизәйткеч)

Иртән торып карап йөрдем
Өй түбәсе-чорманы.
Шунда күрдем чормадагы
Нәни тимер торнаны.
Аннан ачы торма бирдем
Чормадагы торнага.
Ә торманы кадап алдым
Иске тимер тырмага.
Тырмадагы торма белән
Чормадагы торнаны
Сыйласам да, тимер торна
Урыныннан тормады.

Мин ясаган Кар бабай

Мин ясаган Кар бабайга
Бөтен урам сөенә,
Чөнки ул чын кеше кебек
Сөйләшә, җырлый белә.
Йә кинәт көлеп җибәрә,
Скрипка сыздыра.
Йә ул сандугач шикелле
Чут-чут дип сайрап тора.
Матур итеп шигырь укый,
Мәзәк сөйләп көлдерә.
Хәтта һава торышын да
Бер көн алдан белдерә.
Бу Кар бабайны ясавы
Кыен булмады һич тә;
Нәни транзисторымны
Куеп калдырдым эчкә.





Җебек түгел

Саралан дигән авылда
Җәй шундый матур иде.
Кояш бик тә якты иде,
Урман өсте нур иде.

Чәчәкләр күп үскән иде...
Дулап үскән кычыткан.
Шушы кычытканнан инде
Барыбызның кот чыккан.

Ә Миләүшә кычытканны
Ялан кул белән өзде.
Кулы бик тә кычытса да,
Курыкмады ул, түзде.

Казаннан килгән Миләүшә
Җебек түгел, гайрәтле.
Кычыткан тотарга аны
Күрше Ләйсән өйрәтте.

Кызык эзлим


Мин урамда йөрим бүген —
Кешеләр күрәләрдер.
Бәлки әле, минем хакта:
«Эшлексез», — дияләрдер.
Ә минемчә, эшсез булмый
Дөньяда һичбер кеше.
Ялкауның да үз эше бар,
Эшсезлек аның эше.
Ләкин мин ялкау түгелмен,
Эшлексез түгелмен мин.
Мин кызыклар эзләп йөрим —
Эшем шул минем бүген.
Мәйданнарга килеп чыгам,
Фонтан астына керәм,
Чәчәкләр белән сөйләшәм,
Сөйләшәм өйләр белән.
Бакчада уйнап йөрүче
Нәни кызларны дәшәм
Һәм аларның һәрберсенә
Чуерташлар өләшәм.
Болар бар да кызык миңа —
Эшлексез түгелмен мин.
Мин кызыклар эзләп йөрим —
Эшем шул бүген минем.



Атлас һәм «Атлант»

(Тел күнектергеч)

Аты атлап барганда да
Атлас аңа атлана.
Аның ап-ак яллы аты
Атлант диеп атала.
Атлас аңа атлана да
Китә атлар сакларга.
Барып җиткәч, Атлантны да
Җибәрә ул утларга.
Атлар кырга таба чапса,
Атлас тагын атлана
Ап-ак яллы ак тулпары,
Акыллы ат — Атлантка.
Атлас җилдәй җилеп бара,
Атлант уктай атыла.
Алты малай авыз ачып
Кызыгып карап тора.





Дүрт әтәч

Юл өстендә тузан уйный —
Ике яшь әтәч талаша.
— Безнең әтәч җиңә, — ди-ди
Ике малай якалаша.

Кычыткан

Читән буен сарып алган
Куе яшел кычыткан.
Тик торганда өтеп алды —
Әллә кулы кычыткан.

Кадерле дускай!

Синең матур җырлар җырларга, һичъюгында, авыз эченнән яисә күңелдән генә булса да көй көйләргә яратканыңны чамалыйбыз. Чамаламаска: көн саен радиодан яисә телевизордан җырчы абый-апаларның, яшьтәшләрегезнең җырлавын яратып тыңлыйсың ич инде. Әле үзең дә үскәч җырчы булырга телисеңдер. Өлкәннәргә, дус-ишләреңә бу хакта әйтергә генә кыймыйсыңдыр. Оялма, кыюрак бул. Халкыбызның күңел җәүһәренә әйләнердәй җырлар җырларга өйрән. Уңышлар сиңа!

Ә хәзер синең игътибарга бер борынгы җыру тәкъдим итәбез. Бу җыр 1914 елда Башкортостан төбәгендә язып алынган.

Җирән кашка

Җәйләүләргә чыгып бияләр саудым
Баш күнәкәй,
Баш күнәкәйләрне лә кулга алып.
Җирән кашка аткаем да,
Башын чайкый малкаем,
Алларында солысы беткән —
Сызыла йөрәк майкаем,
И сызыла йөрәк майкаем.
Исән генә йөреп, сау кайтырга
Без китәбез,
Без китәбез илләрдин кузгалып.
Җирән кашка аткаем да,
Башын чайкый малкаем,
Алларында солысы беткән —
Сызыла йөрәк майкаем,
И сызыла йөрәк майкаем.

Күнәкәй (күнәк) - савыт, тәпән.

Рәссам Сергей АНДРИАНОВ

Александр Сергеевич Пушкин

Моннан 200 ел элек Александр Сергеевич Пушкин дигән зур шагыйрь беренче мәртәбә дөньяга аваз салган.

Сез аның бик күп шигырьләрен, әкиятләрен беләсез инде. Еллар берсе артыннан берсе уза торса да, аның шигъри юллары һаман да безнең күңелләрне тетрәндерә әле. Кәефсез чакта да укыйбыз Пушкинны, күңел көр вакытта да аның шигырьләре җанга рәхәтлек бирә.

Пушкин үзе турында болай дип язган:

Һаман яна йөрәк һәм ярата,
Яратмыйча яши алмый ул.

Кайнар йөрәкле шагыйрь булган ул. Кешеләрне чын күңелдән яраткан. Моңа ышанмаган кеше юктыр да әле җир йөзендә. Чөнки шигырьләре шул хакта сөйли.

Шагыйрь һәм язучы — алар бик зур, илаһи көчкә ия кешеләр. Шулай булмаса, Пушкин язган шигырьләр гасырлар аша үтеп, безнең көннәргә кадәр килеп җитә алырлар идеме соң?!!

Кадерле укучым!

Һәр кешенең дә җанында шигърият ята диләр. Шигърият ул матурлык, чисталык һәм мәхәббәт дигән сүз! Кеше гомере буе әнә шуларга тугрылыклы булып яшәргә тиештер!..

Ә без үзебезнең Тукайны бик яраткан кебек, Пушкинны да хөрмәт итәбез, шигырьләрен күңелләрдә йөртәбез.



Царское Село күренеше



Пушкин һәм аның дуслары



Иван Иванович Пущин.

Ваня Саша белән лицейга кабул итү имтиханнары вакытында танышып китә. Һәм алар якын дуслар булалар.

Пушкинны патша әмере белән Михайловское авылына сөргенгә җибәрәләр. Дуслары, патшага ишетелүдән куркып, аның янына бармыйлар. Ә Иван Пущин шүрләп тормый, Грибоедовның «Горе от ума» китабын һәм күчтәнәчләрен ала да Пушкин янына китә.

Дуслар кыен чакта сынала инде ул!



Антон Антонович Дельвиг.

Пушкин аның турында болай дип яза: «Дөньяда аннан да якын кешем юк иде минем». Дельвиг лицейда укыганда ук Пушкинның зур шагыйрь булачагын әйтә. Һәм аның ярдәме белән шигырьләре дә басыла башлый. Ул шагыйрьнең үзенә дә әйтеп тормыйча, аның «Шигырь язучы дустыма» дигән әсәрен «Вестник Европы» журналына юллый. Аннан соң рәссам Кипренскийга да шагыйрьнең рәсемен ясарга Антон куша.

Дельвиг үзе дә шигырьләр яза. Аларның күбесенә көй языла һәм алар матур романсларга әйләнеп китәләр.



Павел Ваннович Нащокин.

Бу егет Пушкинның абыйсы белән бергә укый. Пушкин үзе дә аның белән дуслашып китә.

Нащокин Мәскәүдә яши. Пушкин Петербургтан Мәскәүгә килгәндә гел анда туктала торган була.



Петр Андреевич Вяземский.

Бу кеше шигырьләр яза, яхшы журналист һәм акыллы әдәби тәнкыйтьче була. Аларны Пушкин белән әдәбиятка булган мәхәббәтләре берләштерә...



Габдулла Тукай

Пушкинга

Тиңдәшсез шагыйрь булдың, афәрин, Пушкин Александр!
Минем дәртем һәм омтылышым синең дәртең белән бер үктер.

Минемчә, синең шигырьләрең алдында агачлар һәм ташлар бииләр;
Агачлар биемәслек итеп язу шагыйрь булган кешегә кимчелек.

Ник биемәсеннәр, синең шигырең якты кояш кебек,
Алладан илһам алган нинди (көчле) шагыйрь ул.

Күңелгә каралык килми: синең шигырең аңа каршы,
Гүя дөнья һәм анда булган нәрсәләр кояшка каршы ялтырыйлар.

Бөтен әсәрләреңне укыдым һәм күңелдән ятладым,
Гөл бакчаңа кереп, җимешләреңнән авыз иттем.

Синең бакчаңа кереп, гиздем һәм очып йөрдем,
Сандугачларыңны күреп, күңел ачып йөрдем.

Сүзләреңнән күңелгә хушлык, җанга яктылык килер,
Шулай булмаганда, һичбер кешегә һәйкәл куелмас.

Минем бар теләгем, максатым — синең тезмә һәм чәчмәләрең;
Синең нинди караштa һәм диндә булуыңны тикшерү — минем эшеммени?

Әйе, теләгем бер генә, ләкин миндә аңа ирешү өчен дәрман юк.
Боеру аның кулында булган зат ул дәрманны да бирер.

1906

Искәрмә: Г.Тукайның бу шигыре хәзерге татар әдәби теленә юлга юл тәрҗемә итеп бирелә.

Сабый Пушкин



Шаккатырлык хәл: нәни чагында Александр Пушкин русча бөтенләй сөйләшмәгән диярлек, рус телен дә начар белгән. Ул чакта дворян балаларының теле французча ачыла торган булган шул. Булачак шагыйрьне туган теленә әнисе ягыннан әбисе Марья Алексеевна һәм нянясы (бала багучы) Арина Родионовна өйрәткәннәр.

Кызы Надежда Осиповнаны кияүгә биргәч, Марья Алексеевна Мәскәүгә күчеп килә һәм үзен тулысынча оныкларына багышлый. Беренче оныгы тугач (ә бу бала нәкъ менә безнең Пушкин инде), ул авылдан үзенең крепостноен — Аринаны китертә. Марья Алексеевна үз заманы өчен бик укымышлы, акыллы хатын була, саф иткән рус телендә сөйләшә һәм яза. Ул оныгына борынгылар турында сөйли. Ә Арина Родионовна!.. Анысы инде оста әкиятче, җырчы, такмакчы, бәетче... Аның сөйләгәннәре соңрак Пушкинны атаклы әкиятләрен язарга рухландыра. Нянясы Александрны барлык балалардан артык күреп ярата. Пушкин да бәләкәйдән үк аңа олы ярату белән җавап бирә. Аны гомере буе «мама», «мамушка» (әни, әнкәй) дип йөртә, кайгырта, хатлар язып хәлен белешеп тора, аңа шигырьләр багышлый.



Үземне баккан әбиемә

Яман көннәремдә җан сердәшем,
Талган күгәрченем син минем!
Бер ялгызың урман түрләрендә
Бик күптәннән көтәсең мине.

Күз талдырып һаман карыйсың син
Тәрәзәңнән — якты өеңнән,
Җыерчыклар баскан кулларыңда
Туктап-туктап кала бишинәң.

Кара юлга һаман карыйсың син,
Ябык, онытылган капкага:
Сизенәсең нидер булачагын,
Күңелеңне шомнар актара.

Йә тоела сиңа...

1826 ел.

А.С.Пушкин шигыре
шагыйрь Зөлфәт
тәрҗемәсендә





Ренат Гаффар

МИНЕ ЙОЛДЫЗЛАРДАН ЭЗЛӘГЕЗ...

Мин — Әшнәк авылының зәңгәр күзле акбүз бер бахбае идем. Сабан туеның ат чабышында җаным кыелмаган булса, яшисе идем әле. Үземә атланып та йөрделәр, искереп беткән, дегет күрмәгән арбама утырып та мәш килделәр. Элегрәк очрашкан чакта үзем сыман ап-ак шикәр каптыра иделәр әле. Хәзер бетте инде. Үзләренә дә юк.

Бүген — Сабан туе буласы көн. Элегрәк кешеләрнең шул бәйрәме җитсә, бер атна алдан бии башлый идем. Ничек тик торасың ди инде, җә? Беренче хуҗам — Әшнәкнең иң яхшы бер агае — Галәветдин авылда сөлге җыя башлау белән сыртыма нәни улы Рәисне атландырып куя торган иде. И-и китәбез шуннан көн саен җилдереп, җилләрне дә әллә кайларда калдырып, и-и очабыз. Атна буена ашаганым солы гына. Чабышка кузгалыр алдыннан ярты чиләк йомырка эчертә иделәр. Менә шуңа күрә җиде ел рәттән чабышта беренче килдем дә инде мин.

Аякларым бер генә дә тартмаган иде лә бу юлы. Каршы килеп буламы соң инде? Болынымда утлап, рәхәт чигеп йөргән чыклы бер таңда чит-ят бер йөгән кидереп, авызлык салдылар да, кыйный-кыйный алып киттеләр мине...

Авыл әтәчләре кычкырып туйган бер вакытта Тегермән очында гармун шыңшый башлады. Икенче хуҗам Илдар абый, аның җан дусты — миңа очраган саен тәмле ипи кыерчыгы каптыра торган Себер кешесе Габделбәр агай шул урамда торалар... Ул ара матур киенгән абый-апалар, бала-чага ашыга-ашыга болынга җыйналганын күрдем дә, тагын кешнәп карадым.



— Чаптырмагыз мине! Улкаем-колынкаем кала ич! — диюем иде бу.

...Зәңгәрле авылы чишмәсе янында тезеп куйдылар безне. Иң курыккан нәрсәм булган чыбыркы шартлатып алгачтын киттек инде очып.

Артка кала башлавымны җайдагым һич кенә дә көтмәгән иде. Як-яклап авыр үкчәсе белән типкәли генә бит бу мине. Үзебезнең болынга җитеп килгәндә иң алда очкан иптәшемне куып җиттем бит тәки. Алда — мәйдан. Алдагы көндәш бахбай өстендәге малайны шундук танып алдым. Бу бәләкәй кешене былтыр, арбама утыртып, пычрак ера-ера күрше авылдагы больнискә илтеп җиткергән идем. И сөендем дә соң ул малай исән калгачтын.

Менә шул малай:


— Кая бара! — дип ысылдады, ә аннары чыбыркысы белән күземә сызып алды. Көтмәгән идем. Сөрлегеп тә киттем, җайдагым өстемнән очты да. Юл читендә яткан дәү ташка барып төшә күрмәсен дип мин аның астына мәтәлдем. Эчтә нидер шартлап өзелде. Өстемә күк ишелеп төште...

Машина килеп туктаганын ишетеп калдым әле. Бу теге нәни чагыннан ук миннән калмый йөргән Рәис — кайтмаска дип киткән Галәветдин агай улы.

— Тор инде, тор, аткаем-аккаем, — дип ялына ул. — Мин ич бу...

Тузанда яткан муеныма тәмле исе килеп торган сөлгесен салгач, яңагыма аның күз яше тамып әшү белән әллә кайларга, биеккә-биеккә очыртып алып киттеләр мине. Соң килгән бахбайга дигән яулык, сөлге тоткан апалар кеп-кечкенә булып аста калды. Мин тай чакта ук чапкан болыннар, матур мәйдан баштарак арбамның чалыш көпчәге, ә аннары хуҗамның түбәтәе, тора-бара улкаемның елтыр күзе хәтле генә иде инде.

Мин булып кешеләргә син каласың, колынкаем-аппагым. Әниеңне йолдызлардан эзлә-ә-әү...



Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ





Нури Арслан

Акбүз ат хикәясе

Кайвакытта ерак үткән көннәр,
Бала чаклар били уйларны.
Исләремә төшә Казахстан,
Киң далалар, Иртеш буйлары...

Мал җыялар иде ул елларда:
Иртеш аша, төяп паромга,
Китерделәр бер көн бик күп атлар
Күршедәге бер зур загонга.

Без, малайлар, җыелып утырдык та,
Сарай түбәсеннән карыйбыз:
«Бу минеке, бусын мин алам!» дип,
Үзебезгә атлар сайлыйбыз.

Мин сайладым бер шәп акбүз атны.
Муйнын сузып ул гел карана.
Башка атлар кебек иснәшми дә,
Тибешми дә, керми арага.

Тетри тәне, киек болан кебек,
Күзләрендә сагыш күренә...
Бер омтыла койма буена ул,
Бер ташлана загон түренә.

Тар курага сыялмыйча шулай
Чабып йөргәч дала конаны,
Канатлы ат кебек, көтмәгәндә,
Сикереп чыкты биек койманы.

Ял-койрыгы гына күренеп калды,
Җил җаена тузгып соңгы кат...
Без шаккаттык, ә мин горурланып:
— Менә нинди, дидем, минем ат!

Ул Иртешкә таба чабып китте,
Уйнап калды артта тузаны.
Без барганда инде йөзә иде,
Түше белән ярып суларны.

Малкай, йөзеп чыккач киң елганы,
Каршы ярга басып кешнәде:
Чакыргандай загоннарда калган
Елкыларны — үзенең ишләрен.

Аннан чабып китте даласына.
Бу вакыйга нәни йөрәктә
Нинди горур хисләр уятканын
Әйтеп булмый җырда сөйләп тә.

Ишетелде соңра: ул акбүз ат
Үз иленә кайткан икән, дип,
Туган җире — Зайсан даласында
Үз өерен тапкан икән, дип.

Мин онытмам бер дә ул толпарны,
Ашкынуын аның иреккә.
Ул әле дә кешнәп чакыра кебек
Далаларга, иркен киңлеккә.



Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ



Рөстәм Мингалим

Атланабыз атларга


(Малайлар җыры)

Без бәләкәй чакларда —
атланабыз атларга.
Төшәбез, әй, мәтәлеп
урамнарга, чатларга:
— Ап-па, һоп-па,
без Самара яклары!
Йолдыз белән Дәүләткол,
Усман, Бакай, Балыклы,
Камышлы һәм башкасы
бездән көлә эч кашып.
Без бәләкәй чакларда —
каласы юк атлардан.
Атланабыз яңадан,
мин дә менәм чаптарга:
— Ап-па, һоп-па,
без Самара яклары!
Йолдыз белән Дәүләткол,
Усман, Бакай, Балыклы,
Камышлы һәм башкасы
юл өстенә басмасын.
Без бәләкәй чакларда -
очабыз, әй, атларда.
Үзебезнең кырларда,
мин үземнең чаптарда:
— Ап-па, һоп-па,
Без Самара яклары!
Йолдыз белән Дәүләткол,
Усман, Бакай, Балыклы,
Камышлы һәм башкасы
карый безгә баш кашып.
... Ап-па, һоп-па,
их, Самара яклары!

Велосипед

Шәһәр буйлап
куасың,
әй ашыккан
буласың.
Түбән таба
җиллисең,
үргә таба —
тирлисең.

Велосипедмыни соң —
синең велосипедың?
Барып кара авылга,
вәт минем —
велосипед!
Ак колаклы,
ут койрыклы
ат минем велосипед!



Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ



Айсылу Казан шәһәренең 369 нчы «Алтынчәч» балалар бакчасына йөри. Аңа 6 яшь. Үскәч дөнья гизәргә — Нью-Йоркта йорт салырга, Мисырга барып Клеопатраның картайтмый торган кремын табарга, Париждан затлы сабыннар алырга, Африкада күңел ачып кайтырга һәм авылда яшәп, ат асрарга хыяллана. Рәссам булырына һәм миллион доллар акча эшләячәгенә шиге юк.
Ә шигырьләрне болай,
күңелне кытыклаганга гына яза.



Айсылу Гарипова иҗаты

Әнием

Әнием, бәгырем,
Иң кадерле кешем.
Әнием,
Мин — синең җимешең.

Әнием, кадерлем,
Син — бәгырь бөртегем.
Беркайчан авырма,
Беркайчан кайгырма.

Әнием, сөеклем,
Булыйк без гел бергә.
Гомергә.

Әнием, әнием,
Яратам мин сине.
Мин — синең бөртегең.

Өйнең авызы

Безнең өй сөйләшә белә:
«Күрәсезме,
Айсылу, — ди, —
Бакчадан кайтып килә.»
Өйнең авызы юк дисезме әллә?
Ялгышасыз.
Бар безнең өйнең авызы —
Тәрәзә.




Диңгез. 1999 ел.



Йокыга талган гүзәл.
Март, 1999 ел.




БАШВАТКЫЧЛАР



① Охшаш 2 кыңгырау һәм 2 дуга тап.



② Җитез Кул исемле индеец атны үзенә тартып китергән вакытта бауда ничә төен ясала?





③ Уң яктагы 3 рәсемне сул яктагы буш шакмакларга дөрес итеп куй?

Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Әкият илендә сәяхәт

1. Оча торган тәмлетамак. (Мультфильм герое.)
2. Киемен әйләндереп киюче шаян кеше. (Татар халык әкияте герое.)
3. Могҗизалар илендә булган кыз.
4. Зур колаклы бәләкәй җан иясе, крокодилның дусты. (Мультфильм герое.)
5. Шәүкәт Галиевнең шигъри малае.
6. Кәҗәнең юлдашы. (Г.Тукай әкиятеннән.)
7. Киртәгә менәргә яратучы кош.
8. Хәйләкәр җәнлек.
9. Урман сарыгы. (Г.Тукай әкиятеннән.)
10. Суган-бала. (Д.Родари әкияте герое.)
11. Кире малай. (Р.Хафизова әкиятеннән.)
12. Сертотмас. (А.Алиш әкиятеннән.)
13. Эшсөяр бал корты. (А.Алиш әкиятеннән.)

Л.Гыйльфан төзеде.



Салават күпере

5-6(111-112) — 1999

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГЪЛҮМАТ ҺӘМ МАТБУГАТ МИНИСТРЛЫГЫ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ИДАРӘСЕ ҺӘМ РЕДАКЦИЯ ЖУРНАЛЫ
1990 елның март аеннан бирле чыга

"Салават купере" ежемесячный журнал Министерства информации и печати РТ, правления Союза писателей РТ и редакции. На татарском языке.
Основан в 1990 году.

Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы тарафыннан 96 нчы номер белән теркәлде

Баш мөхәррир
Зиннур ХӨСНИЯР

Баш мөхәррир урынбасары
Фирая БӘДРЕТДИН

Бүлек мөхәррире
Ләбиб ЛЕРОН

Бизәлеш мөхәррире
Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Компьютер дизайны
Мөнирә КУЗИЕВА

Исәп-хисап бүлеге
Рәмзия САЛИХ

Тышлыкның 1нче битендә
Фәрит МУЛЛАХМӘТ рәсеме

Адрес редакции:
420012 г. Казань, ул. Муштари, 14.


«Салават күпере» журналының компьютер үзәгендә җыелды һәм тесләргә бүленде.

Татарстан газета-журналлар нәшрияты. Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт

Производствога бирелде 21.6.99 ел.
Басарга кул куелды 21.6.99 ел.
Кәгазь форматы 84х108 1/16.
Басма табак 1,5 (2,1).
Офсет ысулы белән басылды.
Тиражы 17000 данә. Заказ 3-297
Бәясе килешү буенча.

POINT®

Бәясе килешү буенча
Индекс 73953



— Көй язабыз бик шәпләп
һәм уйныйбыз әйбәтләп...-



— Чәчәкләр дә матур,
мин дә...

— Мин менә шундый балык
тота язган идем...






Конкурс!
Мин бит бу?!



— Әй, малай,
мин сиңа күз кыстым,
һәм сиңа мин шулай
сүз куштым...



— Сез әйтәсез: «Бу — ни бу?»
Ә мин әйтәм: «Пони бу!»



— Маймыл белән
төштем сурәткә...